СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

29.11.2017　　　с. Русское Макулово　　　43-178

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары турында

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы һәм 29.4 статьясы нигезендә эшләнгән Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативлары турындагы мәгълүматын тыңлаганнан соң, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге халкының яшәү шартларын уңайлы тәэмин итүгә һәм җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешнең мөмкин булган минималь күрсәткечләрен һәм мондый объектларның территориаль яктан мөмкин булган максималь күләменең исәп-хисап күрсәткечләрен билгеләүгә юнәлдерелгән озак сроклы шәһәр төзелеше сәясәте булдыру максатларында,

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегендә шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советының җир мәсьәләләре, төзекләндерү һәм табигый байлыклар буенча даими комиссиясенә йөкләргә

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　А. И. Матвеева